**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**КАРАР**

2019 елның «18» апреленнән № 106

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез мөлкәт объектлары турындагы мәгълүматны бастырып чыгару тәртибен раслау турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Россия Федерациясе Дәүләт Советының 2018 елның 5 апрелендәге утырышы нәтиҗәләре буенча Россия Федерациясе Президенты йөкләмәләре исемлеген (№ПР-817ГС, 15 май 2018 ел) гамәлгә ашыру максатларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль милектә булган объектлар турындагы мәгълүматны бастырып чыгаруны һәм актуальләштерү максатында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез мөлкәт объектлары турындагы мәгълүматны бастырып чыгару тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы рәисенә йөкләргә.

**Яңа Чишмә муниципаль районы**
**Башкарма комитеты җитәкчесе** **Р.Р. Фәсахов**

Яңа Чишмә
муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе
Карары белән расланган 106
«18» нче апрель 2019 ел

**Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез мөлкәт объектлары турындагы мәгълүматны бастырып чыгару Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – Интернет челтәре) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы милкендә булган күчемсез милек объектлары турындагы мәглүмат белән кызыксынган затлар даирәсенә файдалану мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, мәгълүмат бастырып чыгару процедурасын билгели.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә муниципаль берәмлекләр милкендә булган күчемсез милек объектлары турындагы мәгълүматны Интернет челтәрендә бастырып чыгару өчен муниципаль берәмлекнең рәсми сайты булып, http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ сайты тора.

3. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль берәмлекләре милкендәге күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат бастыруга вәкаләтле орган - Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре палатасы.

4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре милкендә булган муниципаль милек реестрына кертелгән күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат, шулай ук Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре милкендә булган җир участоклары турында мәгълүмат бастырып чыгарылырга тиеш. Россия Федерациясе законнары нигезендә чикләнгән мәгълүмат бастырып чыгарылырга тиеш түгел.

5. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы авыл җирлекләре милкендә булган күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат әлеге Тәртипнең 1,2 нче Кушымталары нигезендә күчемсез милек объектлары турында Мәгълүмат рәвешендә бастырылырга тиеш.

6. Мәгълүмат бирү кызыксынган затларның язма мөрәҗәгатьләре буенча, шул исәптән аерым милек объектлары буенча да гамәлгә ашырыла. Муниципаль милек реестрында теркәлгән аерым милек объектлары буенча мәгълүмат кызыксынган затларның Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль милке Реестрыннан өземтә формасында бирелә.

7. Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль милектәге күчемсез милек объектлары турындагы мәгълүматны бастырып чыгару күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматлар һәм Яңа Чишмә муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы күрсәтә торган Яңа Чишмә муниципаль районы һәм Яңа Чишмә муниципаль районының авыл җирлекләре муниципаль мөлкәте реестрына кертелгән мәгълүматлар нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының авыл җирлекләре белән төзелгән килешүләр нигезендә башкарыла.

8. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы милкендә булган күчемсез милек объектлары турында бастырып чыгарылган мәгълүматны актуальләштерү квартал саен, хисап чорыннан соң килүче айның 10 нчы числосына кадәр вәкаләтле орган тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
милкендәге күчемсез мөлкәт объектлары
турындагы мәгълүматны бастырып
чыгару Тәртибенә 1нче Кушымта
2019 елның «18» апреленнән № 106

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль берәмлекләр милкендәге күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат

| № | Милекнең атамасы | Урнашкан урыны (адресы) | Мәйданы кв.м. | Куллану максаты | Йокләнүлелек | Чикләмәлелек |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
милкендәге кучемсез мөлкәт объектлары турындагы мәгълүматны
бастырып чыгару Тәртибенә 2нче Кушымта
2019 елның «18» апреленнән № 106

## Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы муниципаль берәмлекләр милкендәге җир кишәрлекләре турында мәгълүмат

| № | Милекнең атамасы яки кадастр номеры | Урнашкан урыны (адресы) | Мәйданы кв.м. | Җирләрнең категориясе | Максатчан билгеләнеше (куллану рөхсәт ителгән) | Йокләнүлелек | Чикләмәлелек |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |
| | | | | | | | |